РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ
КОМИТЕТ ТЮЛЯЧИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

ТЕЛӘЧЕ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ

КАРАР

«17» март 2022г.

с. Тюлячи

№ 40

Теләче муниципаль районы Башкарма комитетының 2020 елның 12 февралендәге 49 номерлы «Теләче муниципаль районы территориясендә аларны гамәлгә ашыруга вәкаләтле Теләче муниципаль районы Башкарма комитетының муниципаль контроль һәм структур бүлекчәләре төрләре исемлеге турында» карарын үз көчен югалткан дип тану хакында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Теләче муниципаль районы Советының 2021 елның 7 октябрендәге 79 номерлы «Теләче муниципаль районында җирле әһәмияттәге махсус саклanылучы табигать территорияләреннән файдалану һәм аларны саклау өлкәсендәге муниципаль контроль турында нигезләмәне раслау хакында» карары, Теләче муниципаль районы Советының 2021 елның 7 октябрендәге 78 номерлы «Теләче муниципаль районында муниципаль урман контроле турында нигезләмәне раслау хакында» карары, Теләче муниципаль районы Советының 2021 елның 7 октябрендәге 76 номерлы «Теләче муниципаль районы составына керүче авыл җирлекләре чикләрендә муниципаль җир контроле турында нигезләмәне раслау хакында» карары, Теләче муниципаль районы Советының 2021 елның 07 октябрендәге 75 номерлы «Автомобиль транспортында, шәһәр җир өсте электр транспортында һәм юл хуҗалыгында муниципаль контроль турындагы нигезләмәне раслау хакында» карары, Теләче муниципаль районы Советының «Теләче муниципаль районы территориясендә муниципаль торак контроле турында нигезләмәне раслау хакында» 2021 елның 7 октябрендәге 74 номерлы карары, Теләче муниципаль районы Советының 2021 елның 7 октябрендәге 73 номерлы «Теләче муниципаль районы территориясендә җылылык белән тәэмин итү объектларын төзү, реконструкцияләү һәм (яисә) модернизацияләү буенча бердәм җылылык белән тәэмин итүче оешма тарафыннан җылылык белән тәэмин итү объектларын төзү, реконструкцияләү һәм (яисә) модернизацияләү йөкләмәләрен үтәүне раслау турында» карары, Теләче муниципаль районы Советының 2021 елның 7 октябрендәге 72 номерлы «Теләче муниципаль районы авыл җирлекләрендә төзекләндерү өлкәсендә муниципаль контроль турындагы нигезләмәне раслау хакында» карары нигезендә, Теләче муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Теләче муниципаль районы Башкарма комитетының 2020 елның 12 февралендәге 49 номерлы «Теләче муниципаль районы территориясендә аларны гамәлгә ашыруга вәкаләтле Теләче муниципаль районы Башкарма комитетының муниципаль контроль һәм структур бүлекчәләре төрләре исемлеге турында» карарын үз көчен югалткан дип танырга.

2. Әлеге карар гамәлдәге законнар нигезендә үз көченә керә.

3. Әлеге карарны гамәлдәге законнар нигезендә бастырып чыгарырга.

Җитәкче И.Х. Хәмидуллин